ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАР

15 гыйнвар 2021ел. №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк түләү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк түләү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы_______________Ф.М.Фаттахов.

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк түләү тәртибе турында Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк түләү тәртибе турында Нигезләмә (алга таба – бер мәртәбә бирелә торган бүләк, Тәртип) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарында (алга таба – җирле үзидарә органы) муниципаль хезмәт вазыйфаларын билгән муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексының (алга таба – Кодекс) 28 статьясында билгеләнгән шартларда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алырга хокуклы.

3. Әлеге Тәртипнең максатлары өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, Кодексның 28 статьясында каралган нигезләр буенча, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч яисә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгәндә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән (алга таба – муниципаль хезмәт) азат ителү аңлашыла.

4. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнә торган күләмдә бер мәртәбә бирелә торган бүләк бирелә.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

5. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль хезмәттән киткәндә, муниципаль хезмәткәргә, 15 ел муниципаль хезмәт стажы булганда, эштән азат итү көненә билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча айлык акчалата хезмәт хакының биш тапкыр күләмендә һәм муниципаль хезмәтнең киләсе тулы һәр елы өчен – өстәмә рәвештә 0,5 әр хезмәт хакы күләмендә, әмма муниципаль хезмәткәрнең 10 айлык хезмәт хакыннан артмаган күләмдә бер мәртәбә бирелә торган бүләк түләнә.

6. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк түләү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе – яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан кабул ителә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында җирле үзидарә органы карары кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләк муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгәнче хезмәт итә торган җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең эштән азат ителгән (соңгы эш көне) көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

8. Бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләк күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата хезмәт хакы составына түбәндәгеләр кертелә:

- вазыйфаи оклад;

- класслы чин өчен айлык өстәмә;

- муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

9. Бер мәртәбә бирелә торган бүләк бер тапкыр түләнә. Гражданин тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан соң муниципаль хезмәткә алынганда һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктатылгач, әлеге Тәртиптә каралган бер мәртәбә бирелә торган бүләк кабат түләнми.